**Татарстан Республикасы**
**Апас муниципаль районы**
**Урта Балтай авыл җирлеге Башкарма комитеты**

КАРАРЫ

2018 ел, 21 май N6

Урта Балтай авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән буйларын һәм юл буйларын билгеләү һәм куллану Тәртибенә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру гомуми принциплары турында" 2003елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә автомобиль юллар һәм юл эшчәнлеге һәм Россия Федерациясенең аерым актларына үзгәрешләр кертү турында" 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Урта Балтай авыл җирлеге Башкарама комитеты карар бирә:

1. Урта Балтай авыл җирлеге Башкарма комитетының 2014 елның 16 июнендәге 10 номерлы карары белән расланган Урта Балтай авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына бүлеп бирелгән буйларын һәм юл буйларын билгеләү һәм куллану Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.3.4 нче пунктта "стоянка өчен мәйданчыклар белән һәм" сүзләрен "стоянкалар һәм урыннар белән" дигән сүзләргә алыштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында һәм махсус мәгълүмат стендларында авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җирлек Башлыгы**